КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 сентябрь г.Казань № 714

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче; 2022 ел, 25 октябрь, 1137 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы, 2024 ел, 7 май, 311 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.5. Профилактик чаралар үткәрү турында карарларны Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы, Министрлыкның территориаль идарәләре башлыклары - Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге баш дәүләт инспекторы урынбасарлары кабул итә.

Контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карарларны Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы кабул итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин